| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 ноябрь 2024 ел** Күгеш авылы **№24**

Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б " пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, шулай ук җирлекнең Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорты мәгълүмат стендында (җирлек администрациясе бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы:** **А.А. Гатауллин**